КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 408

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2007 ел, 5 февраль, 32 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 30 декабрь, 1141 нче; 2020 ел, 13 июль, 584 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2007 ел, 5 февраль, 32 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 31 май, 408 нче
карары редакциясендә)

Эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен
махсус эш урыннарын булдыруга чыгымнарының
бер өлешен каплауга субсидияләр бирү
тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы һәм «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары нигезендә эшләнгән һәм эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары булдыруга чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидияләр) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Бу Тәртиптә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

эш бирүчеләр – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы һәм Татарстан Республикасы бюджетына салым түләүче, инвалидларны эшкә алу өчен квота билгеләнгән юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), индивидуаль эшмәкәрләр;

квота – эш бирүче тарафыннан эшкә урнаштырылырга тиешле инвалидларны эшкә алу өчен эш бирүченең исемлектәге уртача хезмәткәрләре саныннан процентларда билгеләнгән эш урыннары саны;

махсус эш урыннары – агымдагы елга эш бирүче тарафыннан инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота чикләрендә булдырылган, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен хезмәтне оештыру буенча өстәмә чаралар (төп һәм ярдәмче җиһазны, техник һәм оештыру җиһазын, өстәмә җиһазны адаптацияләүне һәм, инвалидларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, техник җайланмалар белән тәэмин итүне кертеп) үткәрүне таләп итә торган эш урыннары.

1.3. Субсидия бирү максаты – инвалидларны махсус эш урыннарында эш белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру.

Субсидия Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан субсидия алу өчен эш бирүчеләр тарафыннан эш бирүчеләрне сайлап алуда катнашуга җибәрелгән тәкъдимнәрне (заявкаларны) соратып алу ысулы белән үткәрелә торган сайлап алу (алга таба шул ук эзлеклелектә – заявка, сайлап алу) нәтиҗәләре буенча, эш бирүче-

ләрнең сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килү-килмәвеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып бирелә.

1.4. Эш бирүчеләрнең субсидия биреп каплана торган чыгымнары юнәлешләренә сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган елның 1 гыйнварыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән заявкалар бирү тәмамлану датасына кадәрге чорда эш бирү тарафыннан башкарылган түбәндәге чыгымнар керә:

җиһазлар (эш урынын җиһазландыру өчен кирәкле махсус җиһаз, техник һәм тавышны изоляцияли торган (визуаль, акустик, тактиль) җайланмаларны кертеп) сатып алу, аларны монтажлау һәм урнаштыру;

бозылган функцияләрен һәм тормыш эшчәнлегендәге чикләүләрен исәпкә алып, инвалидлар өчен эш урынын җиһазландыруга махсус аудиопрограмма, тавыш көчәйтә торган махсус җайланма, махсус программа тәэминаты, техник җайланмалар һәм башка ярдәмче җиһаз сатып алу;

эш урынында хезмәтне оештыру буенча өстәмә чаралар (төп һәм ярдәмче җиһазны, техник һәм оештыру җиһазын, өстәмә җиһазны адаптацияләүне һәм, инвалидларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, техник җайланмалар белән тәэмин итүне кертеп) үткәрү.

1.5. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында (алга таба – бюджет турындагы закон) каралган бюджет ассигнованиеләре күләме һәм тиешле финанс елына субсидия бирү өчен Министрлыкка законнар белән билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Бу Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатка каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Министрлык.

Бюджет турындагы закон проектын, бюджет турындагы законга үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын формалаштырганда субсидия турындагы мәгълүматлар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) урнаштырыла.

1.6. Сайлап алу критерийлары:

эш бирүче тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

эш бирүченең йөкләмәсе аңа субсидия күчерелгән көннән бер ел эчендә булдырылган махсус эш урынында инвалидның мәшгульлеген, тулы мәшгульлек шарты белән (әгәр дә инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында башкасы күрсәтелмәгән булса) тәэмин итү;

эш бирүченең махсус эш урыннарын булдыру чыгымнарының субсидия белән компенсацияләнми, субсидия күләменең кимендә 5 процентын тәшкил итә торган өлеше.

## II. Сайлап алуны үткәрү тәртибе

2.1. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә бердәм порталда, шулай ук Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) урнаштырыла.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә ким була алмаган сайлап алуны үткәрү сроклары (заявкалар бирә (кабул итә) башлау (биреп, кабул итеп бетерү) датасы һәм вакыты), шулай ук сайлап алу этапларын үткәрү срокларын (тәртибен) күрсәтеп, аның берничә этабын үткәрү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 4.2 пункты нигезендә күрсәткечләренә ирешү максаты белән субсидия бирелә торган нәтиҗәләр (алга таба – субсидия бирү нәтиҗәсе);

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә таләпләр һәм әлеге таләпләргә туры килүкилмәвен раслау өчен эш бирүчеләр тарафыннан бирелә торган документлар исемлеге;

эш бирүчеләр тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 2.4 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртипнең 2.6 – 2.8 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

эш бирүчеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота кысаларында эш бирүчеләрнең инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары булдыру чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – Субсидия бирү турындагы килешү) имза куелырга тиешле срок;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) Субсидия бирү турындагы килешүне төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда, шулай ук рәсми сайтта урнаштыруның сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң була алмаган датасы.

2.2. Эш бирүчеләр бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән Министрлыкка бу Тәртипнең нигезләмәләренә аңлатма бирү турында язма соратулар җибәрергә хокуклы. Әгәр әлеге сорату Министрлыкка заявкалар бирү срогы тәмамланган датага кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча кергән булса, Министрлык әлеге сорату кергән көннән биш эш көне эчендә бу Тәртипнең нигезләмәләренә аңлатмаларны язма рәвештә яки электрон документ рәвешендә җибәрә.

2.3. Эш бирүчеләр сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

эш бирүченең салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

эш бирүченең Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне кире кайтару буенча, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмаска тиеш;

эш бирүчеләр – юридик затлар үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы юридик затка, башка юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска тиеш, аларга карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, эш бирүченең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булырга, ә эш бирүчеләр – индивидуаль эшмәкәрләр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмаган булырга тиеш;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында коллегиаль башкарма органның дисквалификацияләнгән җитәкчесе, әгъзалары, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридик зат булып торучы эш бирүченең баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) турында, индивидуаль эшмәкәр (индивидуаль эшмәкәр булып торучы эш бирүче өчен) турында мәгълүматлар булмаска тиеш;

эш бирүчеләр чит ил юридик затлары, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә һәм (яки) финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачу һәм бирү каралмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аларның теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артып киткән Россия юридик затлары булмаска тиеш;

эш бирүчеләр бу Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш.

2.4. Сайлап алуда катнашу өчен эш бирүчеләр Министрлыкка аның тарафыннан расланган форма буенча заявка бирә.

Эш бирүче тарафыннан бирелә торган заявкада эш бирүче турындагы, эш бирүче тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны, эш бирүче турындагы тиешле сайлап алуга бәйле башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга ризалык, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик зат өчен); Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан эш бирүченең субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыру өчен эш бирүченең ризалыгы булырга тиеш.

Заявкага түбәндәге документлар теркәлә:

эш бирүченең гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелә торган барлык үзгәрешләр турындагы документлар күчермәләре;

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яки физик затны индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яисә Юридик затларның (Индивидуаль эшмәкәрләрнең) бердәм дәүләт

реестры язмасы бите күчермәсе;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазе;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты алдында акчалата йөкләмәләре буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау турында эш бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) тарафыннан имза куелган, мөһер белән (мөһере булганда) расланган белешмә кәгазе;

эш бирүченең бу Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган, эш бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) тарафыннан имза куелган белешмә кәгазе;

эш бирүче – юридик затның үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы юридик затка, башка юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, эш бирүченең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын, ә эш бирүче – индивидуаль эшмәкәрнең үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмавын раслый торган, җитәкче (индивидуаль эшмәкәр) тарафыннан имза куелган, мөһер белән (мөһере булганда) расланган белешмә кәгазе;

коллегиаль башкарма орган җитәкчесенә, әгъзаларына, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы затка яки баш бухгалтерга (баш бухгалтеры булганда), индивидуаль эшмәкәрләргә Федераль салым хезмәтенең «Дисквалификацияләнгән затлар реестрындагы мәгълүматларны бирү тәртибен, дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм соратып алына торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазе формаларын раслау хакында» 2014 елның 31 декабрендәге НД-7-14/700@ номерлы боерыгы белән расланган формалар буенча дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм (яки) соратыла торган мәгълүматның булмавы турында белешмә кәгазе;

эш бирүчегә субсидия күчерелгән көннән бер ел эчендә һәр булдырылган махсус эш урынында инвалидның мәшгульлеген, шул исәптән тулы мәшгульлек шарты белән (әгәр инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында башкасы күрсәтелмәгән булса) тәэмин итү йөкләмәсе турында эш бирүченең ирекле формадагы гарантия хаты;

агымдагы елга билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә урнаштыру өчен булдырылган махсус эш урыны (урыннары) булу турында эш бирүченең җитәкчесе

тарафыннан имза куелган, мөһер белән (мөһере булганда) расланган белешмә кәгазе;

бу Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә субсидия күләменең исәп-хисабы, шулай ук эш бирүченең махсус эш урыннарын булдыруга компенсацияләнми торган чыгымнары өлеше турында эш бирүченең җитәкчесе тарафыннан имза куелган, мөһер белән (мөһере булганда) расланган белешмә кәгазе.

Эш бирүче тарафыннан бу пунктның бишенче, алтынчы абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Эш бирүче сайлап алуда катнашу өчен иң күбе бер заявка бирергә мөмкин.

Заявкаларны кабул итү бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Заявкалар кабул итү срогы башланганга кадәр яки заявкалар (шул исәптән аларны почта аша) кабул итү срогы тәмамланганнан соң Министрлыкка кергән, шул исәптән алга таба сайлап алуларны үткәргәндә кергән заявкалар теркәлми һәм кире кайтарылмый, бу турыда Министрлык тарафыннан эш бирүчегә заявка кергән көннән 10 эш көне эчендә заявкада күрсәтелгән адрес буенча язмача хәбәр итә.

2.5. Заявкалар кабул итү срогы тәмамланганга кадәрге чорда эш бирүче заявканы (шул исәптән аңа үзгәрешләр кертү максаты белән) ирекле формадагы гариза нигезендә кире алырга хокуклы.

Әгәр заявкага үзгәреш кертү яңа заявка бирү юлы белән гамәлгә ашырылса яки Министрлык тарафыннан заявканы кире алу турындагы хәбәрнамә заявкалар бирү срогы тәмамланганга кадәр алынган булса, заявкага үзгәреш кертү яки аны кире алу турында хәбәрнамә гамәлдә була.

2.6. Министрлык заявканы кабул итә һәм аны кергән көнендә, заявканың керү датасын, вакытын һәм теркәүгә алынган тәртип санын күрсәтеп, субсидияләр бирү өчен заявкаларны теркәү журналында терки һәм оешмага, заявканың алу датасын һәм теркәүгә алынганда бирелгән тәртип санын күрсәтеп, заявканы алу турында расписка кәгазе бирә. Заявка почта аша кергәндә, ул кергән көнендә заявкаларны теркәү журналында теркәлә, анда Министрлыкка почта аша керү датасы һәм вакыты күрсәтелә.

2.7. Министрлык тарафыннан заявкаларны карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.

Комиссиянең составы һәм Комиссиянең эш тәртибен билгели торган нигезләмәсе Министрлыкның хокукый акты белән раслана.

Комиссия Министрлык хезмәткәрләре арасыннан төзелә. Комиссия составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән кызыксынучы башкарма органнары һәм федераль башкарма хакимият органнары вәкилләре килешү буенча кертелергә мөмкин.

Комиссия заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән соң килә торган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә эш бирүче тарафыннан бирелгән заявка белән документларны керү чиратына карап, шулай ук эш бирүченең бу Тәртипнең 1.6 һәм 2.3 пунктларында билгеләнгән сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килү-килмәвен тикшерә.

2.8. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

эш бирүченең бу Тәртипнең 1.6 һәм 2.3 пунктларында билгеләнгән сайлап алу

критерийларына һәм таләпләренә туры килмәве;

эш бирүче тарафыннан бирелгән заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

эш бирүче тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

эш бирүче тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

## III. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

3.1. Комиссия сайлап алуда катнашу өчен заявкалар кабул итү срогы тәмамланган көннән соң килә торган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә заявка теркәүгә алынганда бирелгән тәртип саны нигезендә, тиешле финанс елына эш бирүчеләргә субсидия бирү өчен Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә сайлап алуда җиңгән һәр эш бирүчегә бирелә торган субсидия күләмен (S) түбәндәге формула буенча билгели:

$$S = N \times C,$$

монда:

N – булдырыла торган махсус эш урыннары саны, әмма квота кысаларында инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш бирүчегә билгеләнгән һәм шуннан артмаган эш урыннары саны;

C – даими бер эш урыны өчен каплау күләме – 73,6 мең сум.

Комиссия бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән срокта Комиссия утырышының беркетмәсен төзи, анда заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны, заявкаларның тәртип саннары, заявкалары кабул ителмәгән эш бирүчеләр турында (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп) мәгълүмат; сайлап алуда җиңгән эш бирүчеләр исемнәре (аларга бирелә торган субсидияләр күләмнәрен күрсәтеп) күрсәтелә.

Комиссия утырышының беркетмәсе нигезендә Министрлык, Комиссия утырышының беркетмәсе төзелгән көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Субсидия бирү турындагы килешү төзелә торган эш бирүчеләрне билгели һәм бердәм порталда һәм рәсми сайтта түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән эш бирүчеләр турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән эш бирүчеләр турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

Субсидия бирү турындагы килешү төзелә торган эш бирүчеләрнең исемнәре һәм аларга бирелә торган субсидияләр күләмнәре.

3.2. Субсидия Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы тарафыннан

билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелә торган Субсидия бирү турындагы килешү нигезендә бирелә.

Субсидия бирү турындагы килешүгә үзгәрешләр кертү яклар килешүе буенча килешүнең (шартнамәнең) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына кушымтада бирелгән форма буенча Субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турындагы килешүне өзү килешүнең (шартнамәнең) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына кушымтада бирелгән форма буенча Субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

Министрлык заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат бердәм порталда урнаштырылган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Субсидия бирү турындагы килешү проектларын эш бирүчеләргә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша аларның заявкаларында күрсәтелгән электрон почта адреслары буенча җибәрә.

Эш бирүче ике нөсхәдә һәм кәгазьдә булган Субсидия бирү турындагы килешүгә имза куя һәм үзенең электрон почтасына Субсидия бирү турындагы килешү проекты килгән көннән соң килә торган өч эш көне тәмамланганга кадәр Субсидия бирү турындагы килешүнең ике нөсхәсен һәм, эш бирүченең махсус эш урыннарын булдыру чыгымнарын раслый торган документлар күчермәләрен, шул исәптән башкарылган эшләрне (күрсәтелгән хезмәтләрне) кабул итү актлары, җиһаз сатып алуга счет-фактуралар, түләү йөкләмәләре, йөкнамәләр күчермәләрен теркәп, Министрлык тарафыннан расланган формадагы эш урынын булдыру турында эш бирүченең имзасы куелган һәм мөһер белән (мөһере булганда) расланган акт проектын Министрлыкка тапшыра.

Эш бирүчедән ике нөсхәдә имза куелган Субсидия бирү турындагы килешүне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Министрлык аларга имза куя һәм Субсидия бирү турындагы килешүнең бер нөсхәсен эш бирүчегә җибәрә.

Әгәр Субсидия бирү турындагы килешү проекты эш бирүченең электрон адресына килгән көннән өч эш көне эчендә эш бирүче тарафыннан аның имзасы куелган Субсидия бирү турындагы килешү һәм эш урынын булдыру турындагы акт проекты Министрлыкка тапшырылмаган булса, эш бирүче Субсидия бирү турындагы килешү төзүдән баш тарткан дип санала.

Субсидия бирү турындагы килешүдә түбәндәге нигезләмәләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидияне күчерү тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече, аңа ирешмәгән өчен җаваплылык, бу Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә хисаплылыкны бирү сроклары һәм формасы, өстәмә хисаплылык (кирәк булганда);

бу Тәртипнең 1.5 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка киметелгән очракта, эш бирүче белән Субсидия бирү турындагы килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән килешеп булмаганда Субсидия бирү турындагы килешүне өзү хакында, Субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт;

эш бирүче тарафыннан субсидияне кире кайтару тәртибе, сроклары, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан эш бирүченең субсидия бирү шартларын, максатын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыру, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан эш бирүченең субсидия бирү шартларын, максатын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә эш бирүченең ризалыгы, эш бирүче тарафыннан бу Тәртип һәм Субсидия бирү турында төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр, Субсидия бирү турындагы килешүнең шартларын бозган өчен җаваплылык;

эш бирүченең кредит оешмаларында ачылган, субсидия күчерелә торган исәп-хисап счеты реквизитлары.

3.3. Комиссия Субсидия бирү турындагы килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә эш бирүчегә бара, булдырылган эш урынының булу-булмавын тикшерә, эш бирүченең махсус эш урыннарын булдыру чыгымнарын раслый торган, бу Тәртипнең 3.2 пунктындагы бишенче абзацы нигезендә тапшырылган документ күчермәләрен, финанс документлары күчермәләрен эш бирүчедәге документларның төп нөсхәләре белән чагыштыра, эш урыны өчен сатып алынган җиһазның эш урынында фактта урнаштырылган җиһазга туры килү-килмәвен тикшерә һәм эш урынын булдыру турындагы акт проектында күрсәтелгән мәгълүматлар дөрес булганда аңа имза куя.

Комиссия эш бирүчегә барган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә эш урынын карау турында беркетмә төзи, анда эш бирүче тарафыннан эш урынын булдыру турындагы акт проектында күрсәтелгән эш урынын булдыру фактын билгели яки эш урынын булдыру турындагы акт проектында күрсәтелгән мәгълүматларның дөрес булмавын күрсәтә.

Министрлык эш урынын карау беркетмәсе төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә эш бирүчегә субсидия бирү турында яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

3.4. Эш бирүчегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

эш бирүче тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 3.2 пунктындагы бишенче абзацында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

эш бирүче тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы фактын билгеләү.

Эш бирүчегә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык тиешле карар кабул ителгән көннән эш көнендә исәпләнә торган өч көн эчендә эш бирүчегә, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, язма хәбәрнамә җибәрә. Шул ук вакытта Субсидия бирү турындагы килешү эш бирүче тарафыннан Министрлыкның аңа субсидия бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамәсе алынган көннән өзелгән дип санала.

3.5. Субсидия, Министрлык счетына эш бирүченең махсус эш урыннарын булдыру чыгымнарының бер өлешен каплау өчен акча кергәннән соң, Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә эш бирүченең кредит оешмасында ачылган хисап счетына күчерелә.

## IV. Хисаплылыкка карата таләпләр

4.1. Эш бирүче квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 10ысыннан да соңга калмыйча, үзенә субсидия күчерелгән көннән бер ел эчендә Министрлыкка килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап кертә.

4.2. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – махсус булдырылган һәр эш урынында инвалидның мәшгульлеген субсидия күчерелгән көннән бер ел эчендә еллык эш вакыты нормасының яртысыннан ким булмаган күләмдә тәэмин итү.

4.3. Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.4. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары эш бирүче тарафыннан субсидия бирү шартлары, максаты һәм тәртибе үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

4.5. Субсидия бирү шартларын, максатын һәм тәртибен бозган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган очракта, шулай ук бу Тәртипнең 4.2 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешмәгән очракта, субсидия эш бирүче тарафыннан Министрлыкның һәм (яки) дәүләт финанс контроле органының тиешле таләпләрен алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемен түбәндәге күләмдә кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар бирелгән, эш бирүче тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта – тулы күләмдә;

һәр эш урыны буенча бу Тәртипнең 4.2 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгән очракта – эш урынын булдыру чыгымнарының бер өлешен каплау суммасыннан 50 процент күләмендә.

4.6. Эш бирүче тарафыннан бу Тәртипнең 4.5 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.